РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
Советы

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы, ул. Пионерская, 1

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы, Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www. karmalinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ                                   КАРАР

от 20.12.2019 г.                                   № 35

Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан
башка бюджетара трансфертларны
Түбән Кама муниципаль районы
бюджетына бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирү Тәртибен расларга (кушымта).

Кармалы авыл җирлеге
башлыгы                                   А.Д. Кубышкин

Кармалы авыл җирлеге Советының
2019 елның 20 декабрендәге
35 номерлы карарына
кушымта

# Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары нигезендә эшләнгән һәм Түбән Кама муниципаль районы бюджетына Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү очракларын һәм тәртибен билгели.

## 2. Башка бюджетара трансфертлар бирү очраклары

Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

1) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру буенча (финанс ягыннан тәэмин ителеше Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш), балаларны карап тоту һәм карау, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту һәм карауны гамәлгә ашыру шартлар тудыру, шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру буенча, шул исәптән аларның тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын да кертеп, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында;

2) төзелгән килешүләр нигезендә Түбән Кама муниципаль районы дәрәҗәсенә тапшырганда, Кармалы авыл җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыруга;

3) көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла – казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны финанс белән тәэмин итүгә, шулай ук Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты раслаган резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен куллану тәртибендә каралган башка чараларга (алга таба - «шәһәр башкарма комитеты»);

4) бюджет турында карарда каралган башка максатларга.

## 3. Башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары һәм тәртибе

1. Бюджетара трансфертлар бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге максатларга бюджет турындагы карарда каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2.
Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен төп бүлүчесе булып Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаменты (алга таба – «финанс органы») тора.

3. Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертларны бүлү бюджет турындагы карар белән раслана.

4. Бюджетара трансфертлар бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе шәһәр башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – «район башкарма комитеты») арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

5. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 1 пункты нигезендә бюджетара трансфертлар бирү җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясындагы 2 пункты нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу турындагы шәһәр башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 2 пункты нигезендә бюджетара трансфертлар РФ Бюджет кодексының 142.5 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 пункты нигезендә төзелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы шәһәр башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге Тәртипнең 2 кисәгендәге 3-4 пунктлар нигезендә бюджетара трансфертлар бирү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

7.1. Башка бюджетара трансфертлар шәһәр башкарма комитеты карары нигезендә һәм шәһәр башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты тарафыннан төзелә торган Килешү (алга таба – «килешү») нигезендә бирелә.

7.2. Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мәсьәләне карау өчен район башкарма комитеты җитәкчесе шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенә, аларны файдалану максатларын һәм соратып алынган сумманы раслаучы исәп-хисапларны күрсәтеп, финанс чаралары бүлеп бирү турында дәлилләнгән мөрәҗәгать юллый.

7.3. Район башкарма комитеты җитәкчесенең район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мөрәҗәгате мөрәҗәгать алынганнан соң 10 көн эчендә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала. Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карар, финанс органы фикерен исәпкә алып, Түбән Кама шәһәре Мэры белән килештереп кабул ителә.

Финанс органы Түбән Кама муниципаль районына башка бюджетара трансфертлар бүлеп бирү турында шәһәр башкарма комитеты карарын һәм район

бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүне рәсмиләштерә.

7.4. Җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр керткәннән соң, шәһәр башкарма комитеты карары һәм Килешү нигезендә, финанс органы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бюджет ассигнованиеләрен җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органы счетына күчерүне башкара.

8. Башка бюджетара трансфертларны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, район башкарма комитет җитәкчесенә, карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, финанс органы тарафыннан әзерләнгән нигезле язмача кире кагу җибәрелә.

## 4. Башка бюджетара трансфертлардан файдаланган өчен җаваплылык һәм контроль

1. Бюджетара трансфертларның максатларын яисә шартларын бозган очракта, тиешле акчалар шәһәр башкарма комитетының язма таләбе буенча биш банк көне эчендә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә шәһәр бюджеты keремена күчерелергә тиеш.
2. Бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган бюджетара трансфертларның калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә җирлек бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.
3. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын финанс органы контрольдә тота. Контроль финанс органына финанс чараларыннан файдалану турында хисап бирү юлы белән башкарыла. Хисап тапшыру вакыты һәм формасы Килешүдә билгеләнә.
4. Килешүдә каралмаган максатларга башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән акчаларны тоту рөхсәт ителми.
5. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.